ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

площадь Советская, д.12, г.Арск, 422000

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Совет мәйданы, 12 нче йорт, Арча шәһәре, 422000

Тел. (84366)3-00-44, факс (84366)3-11-44. E-mail: archa@tatar.ru. www.arsk.tatarstan.ru

# КАРАР

«10» июнь 2020 ел № 442

## Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы башкарма комитетында хезмәтне саклау белән идарә итү системасы турында Нигезләмәне раслау хакында

Россия Федерациясе Хезмәт кодексы, Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгының «Хезмәтне саклау белән идарә итү системасы турында Типлаштырылган нигезләмәне раслау турында» 2016 елның 19 августындагы 438н номерлы боерыгы нигезендә, Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы башкарма комитеты карар бирә:

1. Кушымта итеп бирелгән Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы башкарма комитетында хезмәтне саклау белән идарә итү системасы турында Нигезләмәне расларга.
2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында бастырып чыгарырга һәм Арча муниципаль районы рәсми сайтында (arsk.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.
3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары Р.Р. Мөхәрәмовка йөкләргә.

Җитәкче И.Ә.Галимуллин

Татарстан Республикасы Арча
муниципаль районы
башкарама комитетының
10 июнь 2020 ел, № 442
карарына кушымта

**Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы башкарма комитетында хезмәтне саклау белән идарә итү системасы турында**
**НИГЕЗЛӘМӘ**

I. Гомуми нигезләмәләр

1. Әлеге Нигезләмә Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы башкарма комитетында хезмәтне саклау белән идарә итү системасы турында (алга таба - Нигезләмә) Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы башкарма комитетында (алга таба - Башкарма комитет) хезмәтне саклау белән идарә итү системасы формалашуның төп принципларын һәм системаның структурасын билгели һәм аның функцияләре Россия Федерациясе Конституциясенә, Россия Федерациясе Хезмәт кодексына һәм Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актларына, Татарстан Республикасы законнарына нигезләнә.

2. Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы башкарма комитетында сак белән идарә итү системасы (алга таба - Система) Башкарма комитетның һәм аның структур бүлекчәләренең (юридик зат оештырмыйча) (алга таба - структур бүлекчәләр) хезмәтне саклау, хезмәт эшчәнлеге процессында хезмәткәрләрнең тормышын һәм сәламәтлеген саклауга юнәлдерелгән мәсьәләләр буенча уртак эш - гамәлләрен оештыру һәм ысуллары (методлары) җыелмасыннан гыйбарәт.

3. Система кысаларында хезмәтне саклау мәсьәләләре буенча идарә һәм җайга салу дәрәҗәләре булып структур бүлекчәләр, хезмәтне саклау буенча белгеч һәм Башкарма комитет җитәкчесе тора.

II. Башкарма комитетның хезмәтне саклау өлкәсендә сәясәте

1. Башкарма комитетның хезмәтне саклау өлкәсендәге сәясәте (алга таба - Хезмәтне саклау сәясәте) Башкарма комитет тарафыннан хезмәтне саклау буенча дәүләт норматив таләпләрен һәм үз өстенә ирекле рәвештә алган йөкләмәләрне үтәүне гарантияли.

2. Хезмәтне саклау сәясәте түбәндәгеләрне тәэмин итә:

а) хезмәт эшчәнлеге процессында хезмәткәрләрнең тормышын һәм сәламәтлеген саклау өстенлеге;

б) эш урыннарында хезмәт шартларының хезмәтне саклау таләпләренә туры килүе;

в) һәлакәтләрне һәм хезмәткәрләрнең сәламәтлеге начараю, җитештерү имгәнүләре һәм һөнәри авырулар очракларын кисәтү буенча, шул исәптән

һөнәри куркынычлар (рисклар) белән идарә итү юлы белән, эзлекле һәм өзлексез чараларны үтәү;

г) хезмәткәрләрнең шәхси үзенчәлекләрен исәпкә алу, шул исәптән эш урыннарын проектлау, җиһазларны, инструментларны, чималны һәм материалларны, шәхси һәм күмәк (коллектив) саклану чараларын сайлау, җитештерү һәм технологик процессларны төзү юлы белән;

д) Системаны өзлексез камилләштерү һәм системаның нәтиҗәлелеген арттыру;

- хезмәтне саклау идарәсендә катнашуга һәм хезмәтне саклау таләпләренә туры килә торган хезмәт шартларын тәэмин итүгә алар тарафыннан вәкаләтле хезмәткәрләрне тиешле ресурслар белән тәэмин итү һәм мондый катнашуны бүләкләү юлы белән мәҗбүри җәлеп итү;

ж) мөмкин булган дәрәҗәдә куркынычсыз хезмәт шартларын тәэмин итүдә шәхси кызыксыну;

з) үз эшчәнлеге үзенчәлегеннән чыгып, хезмәтне саклау өлкәсендә башка бурычларны үтәү.

## III. Башкарма комитетның хезмәтне саклау өлкәсендә максатлары

1. Эш бирүченең хезмәтне саклау өлкәсендә төп максатлары (алга таба - максатлар) Хезмәтне саклау сәясәтендә карала һәм эш бирүче тарафыннан әлеге Нигезләмәнең V бүлегендә каралган процедураларны тормышка ашыру юлы белән ирешелә.

2. Системаның төп максатлары:

а) хезмәтне саклау өлкәсендә оешма сәясәтенең төп юнәлешләрен тормышка ашыру һәм аны камилләштерү буенча тәкъдимнәр эшләү;

б) хезмәт шартларын яхшырту һәм хезмәтне саклау программасын эшләү һәм тормышка ашыру;

в) хезмәтне саклау буенча законнарны үтәүне тәэмин итә торган шартлар тудыру, шул исәптән хезмәт процессында кулланыла торган биналарны һәм корылмаларны, җайланмаларны, приборларны һәм хезмәт процессының техник чараларын эксплуатацияләүнең куркынычсызлыгын тәэмин итү;

г) имин хезмәт шартларын формалаштыру;

д) хезмәтне саклау таләпләрен үтәүне контрольдә тоту;

е) хезмәтне саклау буенча укыту һәм белемнәрне тикшерү, шул исәптән, хезмәтне саклауны тәэмин итү өлкәсендә өзлексез белем бирү системасын булдыру һәм камилләштерү;

ж) Башкарма комитетта хезмәт эшчәнлеген башкаручы затлар белән бәхетсезлек очракларын булдырмау;

з) Башкарма комитетта хезмәт эшчәнлеген башкаручы персоналның, затларның сәламәтлеген саклау һәм ныгыту, аларга дәвалау - профилактикалау хезмәте күрсәтүне оештыру, хезмәт режимнарының, җитештерү процессының,

оештыру ялының оптималь ярашуларын булдыру.

## IV. Башкарма комитетның вазыйфаи затлары арасында хезмәтне саклау өлкәсендә вазыйфаларны бүлү

1. Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы башкарма комитеты:

а) хезмәтне саклау таләпләренә туры килә торган хезмәт шартларын тәэмин итүне дә кертеп, хезмәткәрләрнең хезмәтне саклауга хокукларын гарантияли;

б) хезмәткәрләрнең хезмәт һәм ял режимын үтәүне тәэмин итә;

в) хезмәткәрләрне җитештерүдәге бәхетсезлек очракларыннан һәм һөнәри авырулардан, һөнәри куркынычлардан вакытында иминиятләштерүне тәэмин итә;

г) хезмәтне саклау чараларын ресурслар белән тәэмин итүне оештыра;

д) җитештерү биналарыннан, корылмаларыннан, җиһазларыннан куркынычсыз файдалануны, технологик процессларның куркынычсызлыгын оештыра;

Россия Федерациясе Хезмәт кодексы нигезендә, үз акчалары хисабына мәҗбүри (эшкә кергәндә) һәм вакытлы (хезмәт эшчәнлеге дәвамында) медицина тикшерүләре үткәрүне оештыра;

хезмәтне саклауны тәэмин итүгә караган хезмәт бурычларын үтәү өчен кирәкле компетентлылык дәрәҗәсен саклап калу зарурлыгын исәпкә алып, хезмәтне саклау буенча әзерләүне дә кертеп, хезмәткәрләрне укытуның һәм һөнәри әзерләүнең билгеләнгән тәртибен үтәүне тәэмин итә;

з) тиешле квалификация таләпләренә туры килә торган һәм медицина ягыннан күрсәтелгән эшкә туры килмәү билгеләре булмаган затларның мөстәкыйль эшенә рөхсәт бирә;

и) күмәк (коллектив) саклану чараларын сатып алуны һәм аларның эшләвен тәэмин итә;

к) хезмәт шартларын махсус бәяләүне үткәрүне оештыра;

л) эш урыннарында хезмәт шартлары, һөнәри куркыныч дәрәҗәләре, шулай ук аларга бирелә торган компенсацияләр турында хезмәткәрләргә хәбәр итүне гамәлгә ашыра;

м) хезмәтне саклау таләпләре нигезендә хезмәткәрләргә санитар-көнкүреш хезмәте күрсәтүне һәм медицина белән тәэмин итүне тәэмин итә;

н) һәлакәтләрнең, бәхетсезлек очракларының һәм һөнәри авыруларның сәбәпләрен тикшерүдә катнаша, күрсәтелгән сәбәпләрне бетерү, аларны кисәтү һәм профилактикалау буенча чаралар күрә;

о) дәүләт хакимияте органнарына булган һәлакәтләр, бәхетсезлек очраклары һәм һөнәри авырулар турында вакытында хәбәр итә;

п) контроль-күзәтчелек эшчәнлеге нәтиҗәләре буенча дәүләт хакимияте органнары күрсәтмәләренең һәм боерыкларының үтәлешен оештыра;

2. Башкарма комитет хезмәткәрләренең бурычлары:

а) үзенең хезмәт функцияләрен үтәү кысаларында хезмәтне саклау таләпләрен үтәүне, шул исәптән хезмәтне саклау буенча инструкцияләр

таләпләрен, эчке хезмәт тәртибе кагыйдәләрен үтәүне, шулай ук җитештерү, технологик һәм хезмәт дисциплинасын үтәүне, эш җитәкчесе күрсәтмәләрен үтәүне дә кертеп, тәэмин итәргә;

б) эш бирүче юнәлеше буенча медицина, психиатрия тикшерүләрен, химик-токсикологик тикшеренүләрне узарга;

в) хезмәтне саклау буенча, шулай ук җитештерүдә һәлакәтләр һәм бәхетсезлек очраклары нәтиҗәсендә зыян күрүчеләргә беренче медицина ярдәме күрсәтү мәсьәләләре буенча әзерлек үтәргә;

г) хезмәт шартларының һәм хезмәтне саклауның торышын контрольдә тотуда катнашырга;

д) үзенең эш урынын чисталыкта тотарга;

е) эш көне башланыр алдыннан үзенең эш урынын тикшерү;

ж) үзенең эш урынындагы җиһазларының һәм инструментларының төзеклеген тикшереп тору;

з) үзенең эш урынына карата киртәләрнең, саклау җайланмаларының, блокировка һәм сигнализация җайланмаларының, шәхси һәм төркем саклану чараларының булуын һәм төзеклеген, үтү урыннарының, мәйданчыкларның, баскыч җайланмаларының, рәшәкәләрнең торышын, шулай ук аларның чүпләнгән һәм капланган булмавын тикшерергә;

и) үзенең эш урынын тикшергәндә ачыкланган җитешсезлекләр турында үзенең турыдан-туры җитәкчесенә хәбәр итәргә һәм аның күрсәтмәсе буенча эш итәргә;

к) шәхси һәм күмәк (коллектив) саклану чараларын һәм хезмәт куркынычсызлыгын тәэмин итә торган җайланмаларны дөрес кулланырга;

л) үзенең турыдан-туры яки югары җитәкчесенә кешеләр тормышына һәм сәламәтлегенә куркыныч янаучы теләсә нинди хәл турында, һәр бәхетсезлек очрагы турында яки үзенең яисә башка затларның хәле начарлану турында, шул исәптән кискен һөнәри авыру билгеләре (агулану)барлыкка килү турында хәбәр итәргә;

м) һәлакәтләр килеп туган очракта, эш бирүче тарафыннан элек расланган һәлакәтләр килеп туган очрактагы гамәлләр тәртибе нигезендә эш итәргә һәм килеп туган һәлакәтнең үсешен чикләү һәм аны бетерү буенча кирәкле чаралар күрергә;

3. Хезмәтне саклау буенча белгеч:

а) Системаның эшләвен тәэмин итә;

б) эш бирүчедә хезмәтне саклау буенча оештыру эшенә җитәкчелек итә, эш бирүченең структур бүлекчәләре эшен яраклаштыра (координацияли);

в) һәркем файдалана алырлык урыннарда хезмәтне саклау буенча әзерлек үткәрү өчен күрсәтмә әсбаплар һәм заманча техник чаралар урнаштыруны оештыра;

г) Россия Федерациясе Хезмәт кодексы нигезендә хезмәтне саклау өлкәсендә хезмәткәрләрне норматив хокукый һәм методик документлар белән тәэмин итүне контрольдә тота;

д) эш бирүчедә хезмәтне саклау таләпләрен, хезмәтне саклау өлкәсендә хезмәт законнарын, хезмәткәрләрнең хезмәт һәм ял режимнарын, контроль-күзәтчелек чаралары нәтиҗәләре буенча дәүләт хакимияте органнарының күрсәтмәләрен һәм боерыкларын үтәүне контрольдә тота;

е) хезмәт шартларының һәм хезмәтне саклауның торышын контрольдә тотуны гамәлгә ашыра;

ж) эш бирүченең структур бүлекчәләре тарафыннан хезмәт шартларын һәм хезмәтне саклауны яхшырту буенча чаралар эшләүне оештыра, аларның үтәлешен контрольдә тота;

з) хезмәтне саклау мәсьәләләре буенча дәүләт хакимияте органнары белән оператив һәм консультатив элемтәне гамәлгә ашыра;

и) хезмәтне саклау буенча локаль актларны эшләүдә һәм яңадан карауда катнаша;

к) хезмәтне саклау буенча әзерлек оештыруда һәм үткәрүдә катнаша;

л) шәхси һәм күмәк (коллектив) саклану чаралары белән тәэмин итүне, аларны бирүне, саклауны һәм куллануны, аларның төзеклеген һәм дөрес кулланылышын контрольдә тота;

м) хезмәт шартларын махсус бәяләү нәтиҗәләре буенча махсус кием һәм башка шәхси саклану чараларын, юдыручы һәм зарарсызландыручы матдәләрне бирү, эш вакытының дәвамлылыгы, шулай ук хезмәт өчен түләүне арттыру һәм өстәмә ялның дәвамлылыгы нормаларын тикшерә һәм аларны яңадан карау буенча тәкъдимнәр кертә;

н) хезмәт шартларын махсус бәяләүне оештыруда һәм үткәрүдә катнаша;

о) һөнәри куркынычлар белән идарә итүдә катнаша;

п) эш бирүченең структур бүлекчәләрендә хезмәтне саклау торышын тикшерүләр оештыра һәм үткәрә;

р) хезмәткәрләргә медицина, психиатрия тикшерүләре, химик-токсикологик тикшеренүләр үткәрүне оештыра;

с) булган җитешсезлекләрне һәм хезмәтне саклау таләпләрен бозу очракларын бетерү турында күрсәтмәләр (боерыклар) бирә, аларның үтәлешен контрольдә тота;

т) һәлакәтләрне, бәхетсезлек очракларын һәм һөнәри авыруларны тикшерүдә катнаша, алар буенча исәп һәм хисаплылык алып бара, аларның сәбәпләрен анализлый, шундый ук очракларның кабатлануын кисәтү чараларын билгели һәм гамәлгә ашыра, аларның үтәлешен контрольдә тота;

4. Структур бүлекчә җитәкчесе:

а) эш бирүченең структур бүлекчәсендә хезмәтне саклау таләпләренә туры килгән хезмәт шартларын тәэмин итә;

б) Системаның эшләвен тәэмин итә;

в) хезмәтне саклау өлкәсендә үзенә йөкләнгән бурычларны тиешенчә үтәмәгән өчен җавап тота;

г) үз кул астындагылар арасында хезмәтне саклау өлкәсендә вазыйфаларны бүлә, шул исәптән үз вәкаләтләренең бер өлешен күчерә (делегацияли), аларның җаваплылык дәрәҗәсен билгели;

д) вәкаләтле органнар хезмәткәрләре вәкилләре тарафыннан хезмәтне саклау буенча комитет (комиссия) эшендә ярдәм итә;

е) структур бүлекчә хезмәткәрләренең мәҗбүри беренчел (эшкә кергәндә) һәм даими (хезмәт эшчәнлеге барышында) эш бирүче акчалары хисабына медицина, психиатрия тикшерүләрен, химик-токсикологик тикшеренүләрне вакытында үткәрүне тәэмин итә;

тиешле квалификация таләпләренә туры килә торган һәм медицина

ягыннан күрсәтелгән эшкә туры килмәү билгеләре булмаган затларның мөстәкыйль эшенә рөхсәт бирүне тәэмин итә;

з) хезмәтне саклау буенча әзерлек үткәрүне оештыра;

и) махсус кием, махсус аяк киеме һәм башка шәхси саклану чаралары, юдыручы һәм зарарсызландыручы чаралар бирүне оештыра;

к) хезмәтне саклау таләпләре нигезендә структур бүлекчә хезмәткәрләренә санитар-көнкүреш хезмәте күрсәтүне һәм медицина ярдәме күрсәтүне тәэмин итә;

л) структур бүлекчәдә җитештерү биналарын, корылмаларын, җиһазларын эксплуатацияләүнең куркынычсызлыгын, технологик процессларның куркынычсызлыгын оештыра;

м) хезмәт шартларын махсус бәяләүне үткәрүне оештыруда катнаша;

н) һөнәри куркынычлар белән идарә итүне оештыруда катнаша;

о) структур бүлекчәдә һәлакәт хәлләрен булдырмау, структур бүлекчә хезмәткәрләренең һәм башка затларның мондый хәлләр килеп чыкканда тормышларын һәм сәламәтлекләрен саклау буенча чаралар, шул исәптән беренче ярдәм күрсәтү буенча чаралар күрә;

п) структур бүлекчәдә хезмәт шартларының һәм хезмәтне саклауның торышын контрольдә тотуны оештыруда һәм үткәрүдә катнаша;

р) структур бүлекчәдә булган һәлакәтләрнең, бәхетсезлек очракларының һәм структур бүлекчә хезмәткәрләренең һөнәри авыруларының сәбәпләрен тикшерүдә катнаша, күрсәтелгән сәбәпләрне бетерү, аларны кисәтү һәм профилактикалау буенча чаралар күрә;

с) эш бирүчегә структур бүлекчәдә булган һәлакәтләр, бәхетсезлек очраклары һәм структур бүлекчә хезмәткәрләренең һөнәри авырулары турында вакытында хәбәр итә;

т) контроль - күзәтчелек эшчәнлеге нәтиҗәләре буенча дәүләт хакимияте органнары күрсәтмәләренең һәм боерыкларының, хезмәтне саклау хезмәте (белгече) күрсәтмәләренең (боерыкларының) үтәлешен тәэмин итә;

у) структур бүлекчәдә кирәкле приборлар һәм җитештерү процессларын контрольдә тоту системаларының булуын һәм эшләвен тәэмин итә;

ф) структур бүлекчәдә хезмәтне саклау таләпләре белән билгеләнгән очракларда эшләрне туктата;

х) структур бүлекчәләрнең һәркем файдалана ала торган урыннарында структур бүлекчә хезмәткәрләренә һәм башка затларга танышу өчен хезмәтне саклау таләпләрен үз эченә алган документлар һәм мәгълүмат булуын тәэмин итә;

ц) структур бүлекчәдә булган һәлакәтләрдә һәм бәхетсезлек очракларында ашыгыч медицина ярдәмен чакыру һәм зыян күрүчеләрне медицина оешмасына илтеп куюны оештыру буенча чаралар күрә;

## V. Башкарма комитетның хезмәтне саклау өлкәсендә максатларга ирешүгә юнәлдерелгән процедуралары

1. Хезмәтне саклау буенча хезмәткәрләрне әзерләү процедурасын оештыру максатыннан эш бирүче түбәндәгеләрне билгели:

а) хезмәткәрләрнең хезмәтен саклау буенча кирәкле һөнәри

компетентлылыкка, аны тикшерүгә, аңа ярдәм күрсәтүгә һәм үстерүгә таләпләр;

б) стажировканың һәр һөнәр (вазыйфа) буенча дәвамлылыгы күрсәтелеп, хезмәтне саклау буенча стажировка узучы хезмәткәрләрнең һөнәрләре (вазыйфалары) исемлеге;

в) хезмәтне саклау өлкәсендә хезмәтләр күрсәтүгә рөхсәт алган укыту оешмаларында хезмәтне саклау буенча әзерлек узучы хезмәткәрләрнең һөнәрләре (вазыйфалары) исемлеге;

г) эш бирүчедә хезмәтне саклау буенча әзерлек узучы хезмәткәрләрнең һөнәрләре (вазыйфалары) исемлеге;

д) эш урынында беренчел инструктаж узудан азат ителгән хезмәткәрләр (вазыйфалар) исемлеге;

е) эш бирүченең структур бүлекчәләрендә эш урынында хезмәтне саклау буенча инструктаж үткәрү өчен, хезмәтне саклау буенча стажировка үткәрү өчен җаваплы хезмәткәрләр;

ж) хезмәтне саклау буенча инструктаж программасына кертелә торган сораулар;

з) эш бирүченең хезмәтне саклау таләпләрен белүләрен тикшерү комиссиясе составы;

и) эш бирүченең хезмәтне саклау таләпләрен белүләрен тикшерү комиссиясенең эш регламенты;

к) эш бирүче комиссиясендә белемнәрне тикшерүне узу өчен хезмәтне саклау буенча сораулар исемлеге;

л) җитештерүдә һәлакәтләр һәм бәхетсезлек очраклары нәтиҗәсендә зыян күрүчеләргә беренче ярдәм күрсәтү мәсьәләләре буенча әзерлекне оештыру тәртибе;

м) хезмәтне саклау буенча инструктаж оештыру һәм үткәрү тәртибе;

н) эш урынында стажировканы һәм хезмәтне саклау буенча әзерлекне оештыру һәм үткәрү тәртибе.

2. Хезмәтне саклау буенча хезмәткәрләрне әзерләү процедурасын оештыру барышында алар башкарган эшләрнең характерыннан һәм эчтәлегеннән чыгып, хезмәткәрләрне әзерләү кирәклеген, аларның үз вазыйфаи бурычларын имин үтәү өчен кирәкле квалификацияләрен һәм вәкаләтләрен исәпкә ала.

3. Үз эшчәнлегенең үзенчәлегеннән чыгып, эш бирүче һөнәри куркынычлар белән идарә итү процедурасын оештыру максатыннан һөнәри куркынычлар белән идарә итү буенча түбәндәге чараларны гамәлгә ашыру тәртибен билгели:

а) куркынычларны ачыклау;

б) һөнәри куркынычлар дәрәҗәсен бәяләү;

в) һөнәри куркынычларның дәрәҗәләрен киметү.

## VI. Процедураларны тормышка ашыру буенча чаралар планлаштыру

1. Процедураларны гамәлгә ашыру чараларын планлаштыру максатында эш бирүче процедураларны гамәлгә ашыру чаралары планын (алга таба - План) әзерләү, яңадан карау һәм актуальләштерү тәртибен билгели.

2. Планда түбәндәгеләр чагылыш таба:

а) хезмәтне саклау буенча комитет (комиссия) (булган очракта) яисә эш бирүче тарафыннан эш бирүчедә хезмәт шартлары һәм хезмәтне саклау торышына үткәрелгән анализ нәтиҗәләре;

б) процедураларны гамәлгә ашырганда үткәрелә торган чараларның гомуми исемлеге;

в) процедураларны гамәлгә ашырганда үткәрелә торган һәр чара буенча көтелгән нәтиҗә;

г) процедураларны гамәлгә ашырганда үткәрелә торган һәр чара буенча гамәлгә ашыру вакытлары;

д) идарәнең һәр дәрәҗәсендә процедураларны гамәлгә ашырганда үткәрелә торган чараларны гамәлгә ашыру өчен җаваплы затлар;

е) процедураларны гамәлгә ашырганда үткәрелә торган чараларны финанслау чыганагы.

## VII. Система эшчәнлеген һәм процедураларны тормышка ашыру мониторингына күзәтчелек итү

1. Система эшчәнлеген һәм процедураларны тормышка ашыру мониторингын контрольдә тотуны оештыру максатларында эш бирүче түбәндәгеләрне тәэмин итү чараларын гамәлгә ашыру тәртибен билгели:

а) хезмәт шартлары һәм хезмәтне саклау торышының үтәлергә тиешле хезмәтне саклау таләпләренә, хезмәтне саклау буенча килешүләргә туры килүен бәяләү;

б) процедураларның нәтиҗәлелеген һәм эффектлылыгын билгеләү өчен мәгълүмат алу;

в) Системаны камилләштерү буенча карарлар кабул итү өчен нигез тәшкил итүче мәгълүматларны алу.

2. Эш бирүче Система эшчәнлеген контрольдә тотуның һәм процедураларны гамәлгә ашыруны мониторинглауның төп төрләрен билгели, аларга түбәндәгеләрне кертергә мөмкин:

а) эш урынының торышын контрольдә тоту, һөнәри куркынычларны ачыклау, шулай ук даими рәвештә гамәлгә ашырыла торган хезмәтне саклау буенча башка чараларны гамәлгә ашыру, процедураларны гамәлгә ашыру күрсәткечләрен мониторинглау;

б) эш башкаруның периодик характердагы процессларының үтәлешен контрольдә тоту: хезмәткәрләрнең хезмәт шартларын бәяләү, хезмәтне саклау буенча әзерлек, медицина, психиатрия тикшерүләре, химик-токсикологик тикшеренүләр уздыру;

в) һәлакәтләрне, бәхетсезлек очракларын, һөнәри авыруларны, шулай ук үтәлергә тиешле хезмәтне саклау таләпләренә, хезмәтне саклау буенча килешүләргә үзгәрешләрне исәпкә алу һәм анализлау;

г) Система эшчәнлеге нәтиҗәлелеген тулаем алганда контрольдә тоту.

3. Идарәнең һәр дәрәҗәсендә Система эшчәнлеген контрольдә тотуның нәтиҗәлелеген күтәрү һәм процедураларны гамәлгә ашыру күрсәткечләрен мониторинглау өчен, эш бирүче система эшчәнлеген һәм процедураларны гамәлгә ашыру күрсәткечләрен мониторинглауны контрольдә тотуның

баскычлы рәвешләрен кертә, шулай ук Система эшчәнлеген һәм процедураларны гамәлгә ашыру күрсәткечләрен мониторинглауны җәмәгать контролендә тоту мөмкинлеген дә күздә тота.

## VIII. Системаның эшчәнлеген яхшыртуны планлаштыру

1. Системаның эшләвен яхшыртуны планлаштыруны оештыру максаты белән эш бирүче Системаның эшчәнлеген яхшыртуның Системаның эшчәнлеген контрольдә тоту нәтиҗәләреннән һәм процедураларны гамәлгә ашыруны мониторинглаудан бәйлелеген, шулай ук һәлакәтләрне, бәхетсезлек очракларын, һөнәри авыруларны тикшерү нәтиҗәләрен, дәүләт хакимияте органнарының контроль-күзәтчелек чаралары нәтиҗәләрен, хезмәткәрләрнең һәм (яки) алар вәкаләтле органнарның тәкъдимнәрен исәпкә алуның мәҗбүрилеген билгели.

2. Эш бирүче Системаның эшчәнлеген яхшыртуны планлаштырганда Системаның эшләвенең нәтиҗәлелегенә анализ ясый, анда түбәндәге күрсәткечләргә бәя бирелә:

а) хезмәтне саклау өлкәсендә эш бирүченең максатларына ирешү дәрәҗәсе;

б) Системаның Хезмәтне саклау сәясәтендә чагылдырылган эш бирүче бурычларын үтәүне тәэмин итү сәләте;

в) Система эшчәнлегенең нәтиҗәлелегенә алдагы анализ нәтиҗәләре буенча идарәнең барлык дәрәҗәләрендә эш бирүче тарафыннан билгеләнгән гамәлләрнең нәтиҗәлелеге;

г) хезмәтне саклау өлкәсендәге максатларга төзәтмәләр кертүне дә кертеп, Системаны үзгәртү, эш бирүченең хезмәтне саклау өлкәсендәге вазыйфаи затларының бурычларын яңадан бүлү, эш бирүче ресурсларын яңадан бүлү зарурлыгы;

д) Системаны үзгәртү турындагы карарлар кагылачак хезмәткәрләрне вакытында әзерләүне тәэмин итү зарурлыгы;

е) Система эшчәнлеге нәтиҗәлелеген бәяләү критерийларын үзгәртү зарурлыгы.

## IX. Һәлакәтләргә, бәхетсезлек очракларына һәм һөнәри авыруларга әһәмият бирү

1. Эш бирүче куркынычсыз хезмәт шартларын тәэмин итү һәм саклау, җитештерүдә имгәнүләр һәм һөнәри авырулар очракларына юл куймау максатыннан, потенциаль мөмкин булган һәлакәтләрне ачыклау тәртибен, алар килеп чыккан очракта гамәлләр тәртибен билгели.

2. Һәлакәт барлыкка килгән очрактагы гамәлләр тәртибен билгеләгәндә эш бирүче тарафыннан һәлакәткә әһәмият бирү һәм аларның нәтиҗәләрен бетерү буенча гамәлдәге һәм эшләнә торган планнар, шулай ук һәлакәт очрагында түбәндәгеләрне гарантияләү кирәклеге исәпкә алына:

а) һәлакәт килеп чыкканда, элемтәнең эчке системасын куллану һәм һәлакәт нәтиҗәләрен бетерү гамәлләрен координацияләү юлы белән эш зонасындагы кешеләрне яклау;

б) хезмәткәрләрнең эшен туктату һәм/яисә эш урынын кичекмәстән ташлап, куркынычсыз урынга китү мөмкинлеге;

в) һәлакәт шартларында эшне яңартмау;

г) һәлакәт турында, эш бирүченең алар белән ышанычлы элемтәсе турында тиешле вәкаләтле органнарга, хезмәтләргә һәм һәлакәт һәм гадәттән тыш хәлләрне бетерү бүлекчәләренә мәгълүмат бирү;

д) җитештерүдә һәлакәтләр һәм бәхетсезлек очраклары нәтиҗәсендә зыян күрүчеләргә беренче ярдәм күрсәтү һәм кирәк булганда ашыгыч медицина ярдәмен чакырту (яисә эш бирүченең сәламәтлек пункты булганда беренче ярдәм күрсәтү), янгынга каршы чараларны башкару һәм эш зонасында булган барлык кешеләрне эвакуацияләү;

е) һәлакәтләрне кисәтү, аларга әзерлекне һәм алардан килгән зыяннарны бетерүне тәэмин итү буенча чараларны гамәлгә ашыру өчен, чын һәлакәтләргә охшаган шартларда даими күнегүләр үткәрүне дә кертеп, хезмәткәрләрне әзерләү.

## X. Системаның документлары белән идарә итү

1. Системаның документлары белән идарә итүне оештыру максатыннан эш бирүче һәр структур бүлекчә һәм конкрет башкаручы өчен Системаның структурасын, бурычларын һәм хезмәтне саклау өлкәсендәге җаваплылыкны үз эченә алган локаль норматив актларны һәм башка документларны рәсмиләштерү формаларын, хезмәтне саклауны һәм контрольдә тотуны тәэмин итү процессларын, эш бирүченең структур бүлекчәләре арасында Системаның эшләвен тәэмин итә торган кирәкле элемтәләрне урнаштыра (билгели).

2. Система документларын эшләү һәм раслау өчен җаваплы затлар эш бирүче тарафыннан барлык дәрәҗәләрдә дә билгеләнә. Эш бирүче тарафыннан шулай ук Система документларын эшләү, килештерү, раслау һәм яңадан карау тәртибе, аларны саклау вакытлары билгеләнә.

3. Системаның яңадан каралырга, актуальләштерелергә, яңартылырга һәм үзгәрергә тиеш булмаган документларының аерым төре буларак Системаның (язмаларның) контроль исәпкә алу документлары түбәндәгеләрне дә кертеп билгеләнә:

а) Системаны гамәлгә ашырудан килеп чыга торган актлар һәм башка мәгълүмати язмалар;

б) һәлакәтләр, бәхетсезлек очраклары, һөнәри авырулар турында мәгълүматларны исәпкә алу журналлары һәм язу актлары;

в) җитештерү мохитенең һәм хезмәт процессының зарарлы (куркыныч) факторларының йогынтысы турында мәгълүмати язмалар, хезмәт шартларын һәм хезмәткәрләрнең сәламәтлеге торышын күзәтү;

г) Системаның эшчәнлеген тикшерү нәтиҗәләре.